ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

21 10 2022 г. № 741

«Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Түбән Кама муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына (алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 пункты түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«2022 елның 10 октябреннән Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның балалары өчен ата-аналар түләве өлешенең өстәмә компенсациясен билгеләргә:

- икенче ата-анасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган баланың (балаларның) ата-анасына социаль ярдәмнең әлеге чарасы Россия Федерациясе

Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт үтү чорына билгеләнә.

Карар кушымтасына:

1.3. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«- икенче ата-анасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган баланың (балаларның) ата-анасына;

1.4. пунктында «1.2 пунктындагы» сүзләрне «1.3 пунктындагы» сүзләргә алмаштырырга;

2.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Икенче ата-анасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган баланың (балаларның) ата-анасына каралган компенсацияне билгеләү өчен мөрәҗәгать итүче Түбән Кама муниципаль районында компенсация кабул итү һәм аны түләүгә билгеләү буенча вәкаләтле органга компенсация билгеләү турында гариза тапшыра. Компенсация билгеләү турында гаризалар кабул иткән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарыннан алынган белешмәләр белән бергә, Түбән Кама муниципаль районында компенсация кабул итү һәм түләү буенча вәкаләтле органга җибәрелә».

«- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар өчен хәрби хезмәтне тәмамлау».

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарына (Ситдыйков Г.Ф.) тәкъдим итәргә: Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә (Андрианова С.А.) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар исемлеген, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәтне тәмамлаган гражданнар исемлеген җибәрергә.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә (Андрианова С.А.) әлеге карарның 2 пункты нигезендә Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарыннан (Ситдыйков Г.Ф.) кергән белешмәләрне Түбән Кама муниципаль районында компенсация кабул итү һәм аны түләүне билгеләү буенча вәкаләтле органга һәм

Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга тиеш.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккач, үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Мәхмүтов Айзат Гамир улына йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

МКУ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874